РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ НОВОАЛИМОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**12.07.2023** **№ 13**

**«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 29 апрелендәге 4 номерлы Яңа Әлем авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуга карата бердәм таләпләр билгеләү максатыннан, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 22 апрелендәге 4 номерлы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 «индивидуаль торак йортларны карап тоту һәм территорияне төзекләндерү» бүлегендә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«49.9.1. Мөгезле эре терлек, сарыклар, атлар, шул исәптән яшь терлекләрне дә кертеп, бирkаланырга һәм оешкан көтү белән колачланырга тиеш. Торак пунктлар урамнарында терлекләр калдырылганда, терлекләрнең хуҗалары яшел үсентеләргә килгән зыянны һәм терлек көтүгә чыгымнарны каплый».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында « Яңа Әлем авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Яңа Әлем авыл җирлеге
Советы рәисе Р.М. Фахертдинов